**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 28 май № 386

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 23 июль, 324 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 23 июль, 324 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче, 2012 ел, 30 май, 443 нче, 2012 ел, 25 июль, 630 нчы, 2012 ел, 6 ноябрь, 969 нчы, 2013 ел, 7 март, 154 нче, 2014 ел, 16 май, 326 нчы, 2014 ел, 11 август, 580 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы турында Нигезләмәдә:

«4. Министрлык вәкаләтләре» бүлегендә 4.1.70 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.70. Казан, Түбән Кама, Чаллы, Зәй шәһәрләрендә һәм шәһәр тибындагы Урыссу поселогында «Генерирующая компания» ачык акционерлар җәмгыяте, «ТГК-16» ачык акционерлар җәмгыяте, «Түбән Кама ТЭЦ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «ТГК Урыссу ГРЭС» ябык акционерлар җәмгыятенең җылылык белән тәэмин итү чыганакларыннан җирлекләрне һәм шәһәр округларын җылылык белән тәэмин итү системаларының ышанычлылыгын арттыру чаралары системасын билгели.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\386.doc